**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы № 39 03 октябрь 2016 ел.

Мәлбагыш авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Мәлбагыш авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Мәлбагыш авылы башкарма комитетының 2016 елның 26 сентябрендә чыккан 14 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 сентябрендә чыккан 38 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар кабул итте :

1. Мәлбагыш авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 2016 елның 20 ноябре көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Мәлбагыш авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2016 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - авыл җирлеге биләмәсен төзекләндерү өчен ( урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урамнарга һәм йортларга урам исемнәре, йорт номерлары урнаштыру, кечкенэ архитектура формалары кую һәм төзекләндерү) - кышын Мәлбагыш авыл җирлегенә кергән авыллардагы юлларны кардан чистарту өчен, үзарасалым акчасының 16 мең 200 сумы;
   - авыл җирлеге биләмәсендә халыкны су белән тәймин итү – Түбән Якый авылына су кертү буенча проекты документациясен ясату өчен, узарасалым күләменең 103 мең 300 сумы;

   - халыкнын ялын оештыру һәм мәдәни оешмалар хезмәтләрен күрсәтүне тәймин иту өчен шартлар тудыру - бәйрәмнәр уздыру өчен, узарасалым күләменең 18 мең сумы;

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла, хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис И.А.Ахтямова